| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.04.2020 Баулы шәһәре №54

Баулы шәһәрендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны түләттерү белән бәйле мәсьәләләрне җайга салу буенча комиссия төзү турында

Баулы шәһәрендә коммуналь хезмәтләр өчен үз вакытында һәм тулы түләүне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә,

1. Расларга:

- 1нче кушымта нигезендә Баулы шәһәрендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны түләттерү белән бәйле мәсьәләләрне җайга салу комиссиясе составын;

- 2нче кушымта нигезендә Баулы шәһәрендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны түләттерү белән бәйле мәсьәләләрне җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәне.

3. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.Л. Бакиров

Татарстан Республикасы
“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге Башкарма комитетының
2020 елның 13 апрелендә
кабул ителгән 54 номерлы
карарына
1нче кушымта

Баулы шәһәрендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны түләттерү белән бәйле мәсьәләләрне җайга салу комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Бакиров Д.Л. | - «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Шәрифуллин Н.И | - «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге начальнигы; |
| Евдокимова В.В | - суд приставлары хезмәте бүлеге начальнигы, өлкән суд приставы ( килешү буенча); |
| Иванов А.Н. | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге начальнигы ( килешү буенча) |
| Карчиго Д.А. | – "Баулы шәһәре һәм Баулы муниципаль районы идарәче компаниясе" ҖЧҖ юристы (килешү буенча) – комиссия секретаре |
| Козикова Л.В. | – Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Баулы муниципаль районындагы социаль яклау идарәсе начальнигы (килешү буенча); |
| Каһиров Р.А. | – Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге начальнигы; |
| Сәлимов Ф.Ә. | - Баулы шәһәр прокуратурасы прокуроры (килешү буенча); |
| Солтанова Р.М. | – «Баулы шәһәре мәшгульлек һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ директоры (килешү буенча); |

Фәйзуллин Д.Г. – “Наш двор” торак милекчеләре ширкәте коммерцияле булмаган оешма идарәсе рәисе (килешү буенча);

Фролов Д.О. - "Татэнергосбыт" ААҖ директоры (килешү буенча);

Шәймарданов Р.М. – Баулы муниципаль районының «Водоканал» МКП директоры (килешү буенча);

Шевелев Е.Г. - "Газпром теплоэнерго Казан» ҖЧҖ «Баулы» филиалы директоры (килешү буенча);

Хәбибуллин Р.А. – Баулы муниципаль районы "Баулы шәһәре идарәче компаниясе" ҖЧҖ директоры (килешү буенча);

_____________ - «Бөгелмәгаз» эксплуатация-җитештерү идарәсенең Баулы район газ хезмәте начальнигы (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
“Баулы шәһәре” муниципаль
берәмлеге Башкарма комитетының
2020 елның 13 апрелендә
кабул ителгән 54 номерлы
карарына
2нче кушымта

Баулы шәһәрендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны
түләттерү белән бәйле мәсьәләләрне җайга салу
буенча комиссия турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Баулы шәһәрендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны түләттерү белән бәйле мәсьәләләрне җайга салу комиссиясе (алга таба-Комиссия) торак (торак булмаган) бина һәм коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләүләрен җыю дәрәҗәсен күтәрү максатыннан оештырылган.

1.2 Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

2. Төп максат

Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

2.1 Халыктан торак-коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны түләттерү һәм түләүләр җыю дәрәҗәсен арттыру белән бәйле мәсьәләләрне җайга салу;

2.2. Торак урын һәм (яки) коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау һәм анализлау;

2.3. Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар барлыкка килүне бетерүгә һәм булдырмауга юнәлдерелгән тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр эшләү;

2.4. Эшче төркем тарафыннан тәкъдим ителгән торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар барлыкка килүне бетерүгә һәм булдырмауга юнәлдерелгән тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрне тормышка ашыру мониторингы.

3. Хокуклар

3.1 Комиссия хокуклы:

1. үз утырышларында нигезләмә белән билгеләнгән бурычларны хәл итү белән бәйле теләсә нинди мәсьәләләрне карарга;

2. торак фонды, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар җитәкчеләренннән кирәкле мәгълүматларны соратып алырга;

3. барлыкка килгән хәлне һәм бурычлы кешеләргә карата кулланыла торган чараларны аңлату максаты белән, комиссия утырышына бурычлы кешеләрне чакырырга.

4.Комиссия рәисе

4.1. Комиссия утырышын алып бара.

4.2. Комиссия әгъзаларына комиссия карары нигезендә йөкләмә бирә.

4.3. Үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм законнарына, Татарстан Республикасы законнарына таяна.

5. Комиссия әгъзалары

5.1. Ресурс белән тәэмин итүче оешмалар һәм/яки торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне исәпләү һәм җыю буенча эшчәнлекне тормышка ашыручы оешмалар җитәкчеләрен халыктан түләүләр җыю мәсьәләләре буенча тыңлыйлар.

5.2. Ай саен комиссия рәисенә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар һәм башкарылган эшләр турында хисап бирәләр.

5.3. Бурычны киметү буенча күрелә торган чараларның нәтиҗәлелеген билгеләүне исәпкә алып, бурычлар торышының динамикасын анализлыйлар.

5.4. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча барлыкка килгән бурычның сәбәпләре дә карыйлар.

5.5. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлары булган гражданнарга карата (алга таба – түләмәүче, бурычлы) материаллар карый һәм комиссия рәисенә тәкъдим итә.

5.6. Бурычларны түләү мәсьәләләрен хәл итү өчен, Комиссия утырышына биналарның милекчеләрен яки арендага алучыларны чакыралар.

5.7. Түләмәүчеләргә социаль ярдәмнең төрле төрләрен алу, социаль ярдәмнең адреслы чараларын күрсәтү мәсьәләләре буенча консультацияләр бирәләр, аларны алырга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә ярдәм итәләр.

5.8. Түләмәүченең даими эш урыны юк икән, Комиссия халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә түләмәүчене эшкә урнаштыру турында гариза җибәрә.

5.9. Социаль наем шартнамәләре буенча торакны алып торучы белән шартнамәне өзү турында гариза белән судка мөрәҗәгать итү турында карар кабул итәләр.

5.10. Массакүләм мәгълүмат чаралары аша халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып барыла.

5.11. Атна, ай, кварталга халык һәм торак-коммуналь комплекс предприятиеләренең бурычларын киметү буенча чаралар планы эшлиләр.

5.12. Социаль төркемнәр категорияләре буенча бурычлылар исәбен алып баралар (халыкның социаль яктан якланмаган категорияләре, асоциаль кешеләр, идеологик һәм башка карашлар буенча түләмәүчеләр).

5.13. Барлык каралган мәсьәләләр буенча тавыш бирүдә катнашалар;

5.14. Комиссия эшчәнлеге өлкәсенә караган сорауларны һәм тәкъдимнәрне комиссия каравына чыгаралар.

6. Комиссия эше тәртибе

6.1. Комиссия утырышлары комиссия секретаре тарафыннан әзерләнә торган көн тәртибе нигезендә үткәрелә. Утырышның көн тәртибе, шулай ук кирәкле мәгълүмат секретарь тарафыннан комиссия әгъзалары игътибарына комиссия

үткәрү датасына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча җиткерелә.

6.2. Комиссия утырышы кирәк булган саен, әмма айга кимендә бер тапкыр уздырыла.

6.3. Комиссия, әгәр аның утырышында составның яртысыннан да ким булмаган өлеше булса, карарлар кабул итәргә хокуклы. Комиссия карары ачык тавыш бирү юлы белән күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссия карары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан раслана, рәис тарафыннан раслана.